Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Багряжского сельского
поселения Заинского
муниципального района

ул. Центральная, д.47а с. Средний
Багряж, Заинский район, 423516

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Баграж авыл җирлегенең
башкарма комитеты

Үзәк урам, 47а йорт, Урта Баграж
авылы, Зәй районы, 423516

Телефон, факс 64-3-42. Электронный адрес: Bagr.zai@tatar.ru, сайт: www.Bagrazh.moy.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.11.2022 ел**

**КАРАР**
**№ 13**

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы номерлы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 мартында 5 номерлы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның электрон формасы кырларын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон формасы кырлары дәрес тутырылмауны ачыклаганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон формада хәбәр итү аша мәгълүмат бирелә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлекләре торак пунктларындагы мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе П.Н. Минеев